«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы карарына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarsian.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе А.Р. Вәлиев



Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы
карары белән расланган
(21.04.2022 № 17-8 карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнары контроль-хисап органы рәисе, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2022 елның 25 февралендәге 15-5 номерлы карарына үзгәрешләр

1) Карарның 1 өлешендә унбишенче абзацтагы «-дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләме (14 нче кушымта).» сүзләрен төшереп калдырырга;
2) Карарга 14 нче кушымтаны (дәүләт серен төзи торган белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәне гамәлгә ашыру һәм аның күләмнәре) бетерергә.
3) Карарның 10 нчы кушымтасының 2 бүлегендәге 2.1 бүлекчәсен (нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләүләрен билгеләү һәм исәпләү турындагы Нигезләмә) «муниципаль хезмәткәрләргә,» сүзләреннән соң «муниципаль хезмәтнең югары, баш һәм әйдәүче вазыйфаларын биләүче» сүзләрен төшереп калдырырга.